Бүгенге санда:



**Парклар һәм скверлар елы дәвам итә.** 4 бит

# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

**Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы**

Җомга **24** июль 2015 ел

№ 53 (10582)

**25 июльгә һава торышы:** болытлы һава, яңгыр, җил төньяк-көнбатыштан, 6 м/с; температура көндез +25°С, төнлә +18°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### КЫР ЭШЛӘРЕН ЯҢГЫРЛАР ТОТКАРЛЫЙ

Соңгы көннәрдә һава торышының яңгырлы торуы кыр эшләре барышын шактый тоткарлады. Шулай да игенчеләр һәр аяз көнне максималь файдаланып эшләргә тырышалар. 23 июльгә районда 985 гектарда игеннәр җыелган, бу планга карата бары 2 процент дигән сүз. Иң зур мәйданнар – 451 га "Сөләйманов Ә.И." КФХсына һәм 350 га "Южная" АФ"сына туры килә. Әлегә басуларда 4 хуҗалык кына чынлап торып эш җәелдерде, калганнары да һава торышы аязайтуга эшкә керешергә әзерләр.

### ЭШЧЕ ТӨРКЕМНЕҢ ИКЕНЧЕ УТЫРЫШЫ ҮТТЕ

Кичә районда аерым категория гражданнарны социаль хезмәтләр белән тәэмин итүне аңлату буенча эшче төркемнең икенче утырышы үтте. Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Әлфия Галәветдинова рәислегендәге әлеге төркем аерым категория гражданнарга социаль хезмәтләр җыелмасының өстенлекләрен аңлату буенча эшчәнлекне активлаштыру һәм нәтиҗәле итү максатыннан оештырылган. Аның составына үзәк хастаханә һәм даруханә, Пенсия фонды, социаль яклау идарәләре, Роспотребнадзор бүлеге һ.б. хезмәткәрләре кертелгән.

### СҮЗ ӘЗЕРЛЕК ТУРЫНДА БАРДЫ

Чәршәмбе көнне район мәдәният хезмәткәрләренең чираттагы семинарында халык җыеннарына әзерлек мәсьәләсе каралды. Моннан тыш, Казан сабантуена әзерлек, җирләрне теркәү кебек сораулар да күтәрелде.

# Күпләр көнләшерлек бәхет



СӘЛАХОВЛАР ГАИЛӘСЕ ҮЗ ЙОРТЛАРЫ ЯНЫНДА

**Соңгы 5 елда Нурлаттан 714 гаилә социаль ипотека буенча фатир алган.**

Күпбалалы Сәлаховлар 2010 елда яңа йорттан өч бүлмәле фатирга ия булганнар. Ул вакытта ике кызлары үсеп килгән инде, ә менә төпчекләре – күптән көтелгән уллары туу зур сөенечтән тыш, ипотека белән тулысынча диярлек исәп-хсап ясау мөмкинлеге биргән: бүгенге көнгә дәүләткә түлисе бурычлары бик аз калган. "Без социаль ипотеканың яшь гаиләләргә шулкадәр отышлы программа икәнлеген уйламаган да идек", – ди Гөлназ Сәлахова. Ул да, ире Илнар да "Татнефть" системасында эшлиләр, бу компания социаль ипотеканы финанслауда катнаша, шуңа да балалары тугач, тиешле 200 мең сумга алар социаль кредитны томалау хисабына квадрат метрларны "сатып алганнар". "Башка төбәкләрдәге дусларыбызга президент акчаларына ипотеканы тулысынча түләп бетердек, дип сөйләгәч, алар ышанмыйлар һәм республикабыздагы мондый мөмкинлекләр булуына бераз көнләшәләр дә", – ди НГДУда 1нче ЦДНГ начальнигы урынбасары булып эшләүче Илнар.

Гомумән, республикадагы Президент программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә күп кенә нурлатлылар тораклы булды. Мисал өчен, соңгы 5 елда ятимнәргә 54 фатир бүлеп бирелде, ә быел әлеге катламнан тагы 17 бала фатирлы булачак. Опека бүлегеннән әйтүләренчә, районда торакка мохтаҗ 173 ятим бала бар, шларның 73е – балигъ булганнар. Әлегә исә аларның кайберләре укый, кайсылары – армиядә. 2010-2015 елларда районнан 700дән артык гаилә соципотека буенча фатир алган, һәм аларның күпчелеге – 370е 2010 елда фатирлы булган, шулардан 78 гаилә бюджет тармагында, 21е соципотеканы финанслаучы предприятиеләрдә эшли, шулай ук 270тән артык сугыш ветераны, инвалидлар, "чернобыльчеләр", "әфганчылар" бар. 2015 елның яртысы гына узды әле, һәм тагы 63 гаилә социаль ипотека буенча фатирлы булды. Тулаем алганда, районда соңгы биш елда 115 меңнән артык квадрат метр торак файдалануга тапшырылды. Төзелеш һәм ТКХ бүлегендә әйтүләренчә, агымдагы ел азагына кадәр тагы 9 мең кв. м. торак төзеләчәк. Димәк, республика программалары буенча тораклы булу бәхетенә ирешүчеләр тагы да артачак.

Сирень **СӘМӘРХАНОВА**

БЛИЦ-СОРАШТЫРУ

# Җиһан игътибары янә Казанга төбәлде

Бүген Казанда су спорты төрләре буенча XVI Дөнья чемпионаты старт ала. Татарстан башкаласында узучы чемпионат әлеге турнир тарихында иң зур масштаблысы булыр дип көтелә. Әлбәттә инде, мондый дөньякүләм чарадан нурлатлылар да читтә калмас дип уйлыйбыз. Без үткәргән блиц-сораштыру да шуны раслады.

**Әлфия Галәветдинова, район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары:**

– Бүген "Татнефть-Арена"да узачак Чемпионатны ачу тантанасына район башлыгы Равил Кузюров чакырулы. Ә 26 июльдә Нурлаттан саллы гына делегация Чемпионатны ачу тантанасында күрсәтелгән "Пилигрим" тамашасын карарга бара. Шул ук "Татнефть-Арена"да узачак шоуны тәрбиягә алынган, күпбалалы һәм опекун гаиләләр балалары, аларның әти-әниләре, шулай ук авыл җирлекләре башлыклары һәм шәһәр башкарма комитеты җитәкчелеге хозур кыла алачак.

**Линар Маняпов, мәгариф бүлеге начальнигы:**

– Районның мәгариф учреждениеләре җитәкчеләреннән торган делегация дә "Пилигрим"ны карап кайтырга ниятли. Мондый мөмкинлекне тырыш һәм нәтиҗәле хезмәт өчен, шулай ук киләчәктә ярышлар уздырганда беркадәр тәҗрибә туплау максатыннан республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы бүләк итә. Шул рәвешле, бездән Дөнья чемпионатын карарга унбишләп мәктәп директоры һәм балалар бакчасы мөдире барырга планлаштыра.

**Татьяна Соренкова, район баш табибы урынбасары:**

– Дөнья чемпионатын уздыруда Нурлат табиблары да читтә калмаячак. Гомумпрактика табиблары – үзәк хастаханәдән Әмил Вәлиев һәм Чулпан участок хастаханәсеннән Галина Паргунькина ярышларда спортчыларның һәм тамашачыларның сәламәтлекләрен кайгыртачак.

**Илсур Нәбиуллин, балалар-үсмерләр спорт мәктәбенең йөзү буенча инструкторы:**

– Барырга дигән анык планнар юк әлегә. Әмма телевизордан, һичшиксез, караячакмын. Үземә йөзү ярышлары ошый. Гомумән, йөзү секциясенә йөрүче балалар белән бу Дөнья чемпионатын зарыгып көтәбез. Кайбер шәкертләребез ярышларны әти-әниләре белән Казанга барып карарга да ниятләп тора.

**Дмитрий Гаврилов, Нурлат:**

– Йөзү ярышларын тыныч кына карый алмыйм, сәбәбе дә бар. Хәтерләсәгез, 1980 елда, Мәскәү Олимпиадасында атаклы спортчыбыз Владимир Сальников 1500 метрга йөзүдә әлегәчә ирешелмәгән дөнья рекорды куйган иде, ә шул төнне безнең улыбыз туды. Әлбәттә инде, аңа Володя дип исем куштык. Казандагы чемпионатка барып, бүгенге көндә илебезнең йөзү федерациясен җитәкләүче легендар Владимир Сальниковтан автограф алырга хыялланам.

*Дөнья чемпионаты исә 16 августка кадәр барачак. Аның ачылу тантанасын бүген 21.00дә "Россия-1" каналыннан карап булачак.*

Илназ **МӨБАРӘКШИН** сорашты

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ШӘҺӘР

## Җылылык челтәрен җәйдән әзерлә




*Электр-газ белән эретеп ябыштыручы Василий Казаков һәм җылылык челтәрләренә хезмәт күрсәтү слесаре Николай Семенов торбаүткәргечкә бүлгеч ябыштыруда. Бу атнада җылылык челтәрләре эшчеләре Гыйматдинов ур., 91нче йорт янәшәсендәге 273 һәм 219 мм.лы торбаларны күбекле-полимер минераль изоляцияләләргә алыштырдылар.*

**Ягу сезоны тәмамланудан башлап бүгенге көнгә кадәр Нурлат җылылык челтәрләре предприятиесе киләсе сезонга әзерлек алып бара. Иң салкын көннәрдә дә шәһәрлеләрнең өйләрендә җылы булсын өчен шактый зур күләмдә җылылык челтәрләре алыштырыла.**

Шулай һәр нюансны күздә тотып әзерләнгәндә генә кышны уңышлы үтеп була бит. Нәкъ менә эшкә җаваплы мөнәсәбәт җылылык челтәрләренә узган кышны аварияләрсез, кулланучылардан шикаятьләрсез үтәргә мөмкинлек бирде дә. Ә бит аларның хуҗалыгы кечкенә түгел.

– Үзәк котельнялардан 228 күпкатлы, 19 шәхси йорт, 8 мәктәп, 10 балалар бакчасы, 8 башкарма һәм суд органнары объекты, поликлиника, хастаханә шәһәрчеге һәм тагы 173 төрле кулланучы җылылык ала, – ди җылылык челтәрләре предприятиесе җитәкчесе Рамил Шарапов. 2012 елдан мәгариф идарәсенең 42 мини-котельнясы арендада, алар исә район мәктәпләре һәм мәктәпкәчә учреждениеләренә генә түгел, Төрнәс авылы халкына да хезмәт күрсәтәләр. "Опрессовка", "Торба үткәргечләрне алыштыру", "Газны исәпкә алу узелларын һәм төтен юллыкларын тикшерү", "Җылылык-механик җиһазларын тоташтыру"–бу терминнар җылылык бирүчеләр теленнән бер дә төшми диярлек. Ике торбалы җылылык челтәрләре озынлыгы 34 км, һәм аларны тәртиптә тоту өчен шактый хезмәт куярга туры килә.

–Бүгенге көнгә җылылык челтәрләренә опрессовка үткәрелде, таушалган участоклар ачыкланды, – ди Рамил Шарапов ике торбалы җылылык челтәрләренең 785 метрда тузган участогы алыштырылуын әйтеп.– Кулланучыларга һәм милекчеләр ширкәтләренә объектларны яңа ягу сезонына әзерләү буенча уведомлениеләр бирелде. Котельня җиһазларына һәм биналарына капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрү буенча эшләр бара. 4 котельняның җылылык-механика һәм электротехник җиһазларын, җылылык алмашу җайланмаларын, насосларны, запор арматураларын ремонтлаганнар, газ исәпләү узелын, КИПиА приборларын, төтен юллыкларын, вентканалларны тикшергәннәр, котельнялар-да заземление контурына һәм электр җиһазларына үлчәү үткәргәннәр. Капиталь ремонт планы буенча 1200 метрда ике торбалы җылылык трассасын алыштыру каралган.

Җиһазларны ремонтлау белән бергә, предприятиедә кадрлар әзерләү юнәлешендә дә эш алып барыла. Бүгенге көнгә, мәсәлән, предприятиенең барлык оператив һәм хезмәт күрсәтү персоналы уку һәм аттестация үткән.

Предприятиедә аренда хокукында торган котельняларны модернизацияләү буенча да зур эш башкарыла. 2012 елдан башлап энергияне күп сарыф итүче насосларны тулысынча экономиялеләргә алыштырганнар. Барлык котельняларда да суны туендыру өчен насослары урнаштырганнар. Аварияләрсез һәм имин эшләү, җылылык җитештерүгә чыгымнарны киметү өчен бу котельняларда технологик процессларны автоматлаштыру һәм диспетчерлаштыру буенча да эш алып барыла. Егоркино мәктәбе һәм "Ивушка" балалар бакчасы котельнялары тулысынча автоматлаштырылган. Тулаем алганда, мәгариф учреждениеләрендә масштаблы эш башкарылган. Бу юнәлештә алар 2015 елга бюджет тармагында казаннарны алыштыру программасы буенча эшлиләр.

– Бу программа кысаларында Иске Чаллы мәктәбе котельнясына реконструкция үткәрдек, ике казан, өч төтен юллыгы, өч казан насосы куеп җылылык-механика һәм электр җиһазлары алыштырылды, –ди предприятие җитәкчесе.– Хәзер Кычытканлы мәктәбе котельнясын реконструкцияләү бара. Шулай ук Биляр Озеро мәктәбендәге котельняны реконструкцияләү эше дә башланды.

Башкарыласы эш аңа бик җитди якын килүне таләп итә. Йортларга һәм учреждениеләргә җылылык җибәргәнче, 15 августта котельняларның ягу сезонына әзерлеген Ростехнадзор инспекторлары тикшерәчәк. 1 сентябрьгә алар әзерлек паспорты алырга тиешләр.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

## ХӘБӘРЛӘР

### БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫ РЕМОНТТА

**Районның 30га якын мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә агымдагы ремонт эшләре бара.**

Бакчаларда ремонт эшләре бер атна барачак, - дип хәбәр итәләр мәгариф бүлегендә. Ремонт чорында агарту, буяу, юу һәм территорияне тәртипкә китерү кебек эшләр башкарылачак.

**Зилия ӘКСАНОВА**

### УЯУЛЫК ФАЙДА БИРӘ

**Дүшәмбе көнне, 13.09да 125нче янгын частеның кизү пультына Гыйматдинов ур., 91 йортның 1нче катындагы фатирда янгын турында хәбәр керә.**

– Бу фатирда ялгыз ир-ат яши, – диде янгын күзәтчелеге бүлегенең өлкән инспекторы Әлмәрис Талипов. – Әлеге пенсионер ваннада көнкүреш җылыту приборы кабызган һәм аны шул көе калдырып китеп барган икән.

Фатирда нидер булганлыгын күршеләр сизеп ала. Янгын частена да алар хәбәр бирә. Кызганычка каршы, ванна бүлмәсенең стеналарындагы пластика тулысынча эреп бетә. Фатирга да "өлеш" чыга – хуҗа кеше җиһаз һәм милкенә утырган корымны тиз генә чистартып бетерә алмас, мөгаен. Ә менә күршеләрнең уяулыгы ярап куйган – аларның фатирларына зыян килмәгән.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

### БЕР УКУЧЫ АТТЕСТАТСЫЗ КАЛГАН

**Быел районда бер укучы Бердәм дәүләт имтиханын тапшыра алмаган, ул – шәһәр мәктәбе чыгарылышы. Узган ел исә 5 чыгарылыш гомумбелем турындагы документсыз калган булган.**

Гомумән алганда, район буенча барлыгы 330дан артык укучы БДИ тапшырган. Район укучыларының имтихан күрсәткечләре яхшырган. Мәсәлән, математика буенча нурлатлылар республика күләмендә 11 урынга менгән.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ВАТАНПӘРВӘРЛЕК

## "Дуслык" Нева мәйданчыгында булып кайтты

**Нурлат ДОСААФының "Легенда" хәрби-патриотик клубы эзтабарлары Бөек Ватан сугышының истәлекле урыннарына чираттагы экспедицияләрен оештырган вакытта район газетасын да алганнар.**

- Бу безнең матур традициягә әйләнде. Хәтер вахтасына җыенганда, һәрвакыт "Дуслык"ның соңгы саннарының берсен үзебез белән алабыз. Газета безнең белән Волгоград өлкәсе Городищенск районы Кузьмичи авылында, "Россошки" мемориаль комплексында барган казылмаларда, ә хәзер Нева мәйданчыгында да булып кайтты, - дип сөйли яшь эзтабар, шәһәрнең 2нче мәктәбенең 9 сыйныф укучысы Андрей Малыгин.

Шушы көннәрдә "Легенда" әгъзалары экспедициядән кайттылар, алар Казан шәһәренең Хәрби Дан клубының җыелма отряды составында Санкт-Петербургтан 40 км ераклыкта урнашкан Кировск шәһәренең Нева елгасы буенда барган казылмаларда катнашканнар. Отрядны Казан Кремленың Бөек Ватан сугышы Музей-мемориал җитәкчесе, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Хәрби-тарихи фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты Михаил Черепанов җитәкләгән. Отряд составына Казан, Нурлат, Югары Ослан, Яр Чаллы һәм Яшел Үзән шәһәрләреннән 40 мәктәп укучысы һәм 30 өлкән кеше кергән.

– Экспедициянең иң яшь катнашучысына 6 яшь иде, ул – Казаннан беренче сыйныф укучысы Влада Пеплова, ә иң өлкән эзтабар Надыйр Хәкимҗановка – 74 яшь, – дип, Нева мәйданчыгындагы сәяхәт вакытында алган тәэсирләре белән уртаклашты "Легенда"ның җитәкчесе Владимир Малыгин. Аны, тәҗрибәле эзтабар буларак, отряд урнашкан палата лагереның коменданты итеп билгеләгәннәр. Гомумән, Михаил Черепанов Нурлат "Легенда"сының эшен югары бәяләгән һәм клуб җитәкчесенә тантаналы җыелышларның берсендә Бөек Ватан сугышының Музей-мемориалы исеменнән "Ленинград камалышын өзүгә 65 ел" истәлекле медален тапшырган. 12 көн дәвам иткән



ЭЗТАБАРЛАР НЕВА МӘЙДАНЧЫГЫНДА

Хәтер вахтасы вакытында отряд 19 солдат медальоны тапкан, ә Ленинградны саклаучыларның сөякләре өчләтә күбрәк табылган.

– Чын эзләнүчеләр моның нәрсә икәнен белә. Шундый табылдыкка юлыгу максатыннан җирне тонналап казу гына җитми, солдат бармагының һәр буынын җыярга, җирне сантиметрлап барлап чыгарга кирәк, – ди Михаил Черепанов.

Экспедиция әгъзаларының тырышлыгы нәтиҗәсендә дистә еллардан соң Нева мәйданчыгында һәлак булучыларның исемнәре торгызыла. Соңгы вахта барышында Красное Село отряды тарафыннан Бөек Ватан сугышы барышында Ленинград янында һәлак булган Нәҗип Вәлиуллинның җәсәде сөякләре табылган һәм туган ягы Азнакай районы Урманай авылында җирләү өчен тапшырылган. Аны исемле медальон буенча таный алганнар. Фронтовик сөякләрен туганнарына тантаналы тапшыру 16 июльдә Казан шәһәре Җиңү Паркының "Хәтер Китабы" мемориаль комплексында узды. Анда "Легенда" әгъзалары да чакырылган иде.

**Маргарита ЛИТТА**

# КӨН АРТЫННАН КӨН

ТАТАРСТАННЫКЫН САЙЛА!



ИКМӘК ПЕШЕРҮЧЕЛӘРГӘ БЕР ДӘ ТИК ТОРЫРГА ТУРЫ КИЛМИ

## Икмәккә ихтыяҗ кимеми

**"Здоровье" җәмгыятенең икмәк заводына көннең кайсы вакытында килсәң дә яңа пешкән кайнар ипинең хуш исе каршы ала. Бу юлы да икмәкнең нәкъ мичтән чыккан вакытына туры килдек.**

Заводның югары һәм 1нче сортлы ипиләренә нурлатлылар гына түгел, тирә-күрше районнар халкы арасында да ихтыяҗ зур. Шуңа да биредә ипиләрне ел әйләнәсе бик күпләп пешерәләр. Хәтта җәйге эсселәрдә дә икмәккә сорау кимеми, киресенчә, арта гына бара.

– Июнь аенда 150 тонна икмәк һәм икмәк-күмәч ризыклары пешердек. Шөкер, барысы да вакытында сатылып бетеп бара, – ди завод директоры Илһам Кәлимуллин. – Эсселәрдә заявкалар күбрәк тә булды әле. Күрәсең, бу Нурлатка читтән дә килүчеләрнең артуы белән бәйледер, бәйрәмнәр дә күп булды бит.

Икмәк заводы Нурлаттагы барлык мәгариф һәм медицина учреждениеләрен икмәк-күмәч ризыклары белән тәэмин итә. Нурлат икмәге шәһәрнең генә түгел, Аксубай, Чаллы Башы районнарында эре һәм вак сәүдә үзәкләрендә дә бик тиз тарала. Икмәктән тыш, биредә батоннар, вак күмәч, камыр ризыклары да күпләп җитештерелә. Әнә, Олеся Питуганова, Нина Захарова, Лариса Помендеева һәм Залия Мөхетдиновадан торган чираттагы бригада күпереп торган камырдан батоннар әвәләү белән мәшгуль. Эш көйле оештырылган, кызларның кулларына күз иярми – мизгел эчендә камыр кисәкләре аркылы сызыклы батоннарга әверелеп, табага тезелә бара. Бу эшләре төгәлләнү белән икенче участокта эш көтә үзләрен – 6 дежада югары сортлы ипи өчен камыр өлгереп килә, аларны да мичкә озатасы булачак, аннан батоннар кабаргач, мичкә тыгасы... Әнә шулай смена буенча тик торырга туры килми үзләренә, өлгер генә!

– Кул хезмәтен җиңеләйтү максатыннан шул араларда автоматлаштырылган он иләгеч урнаштыру белән мәшгульбез, – дип янәшәдә торган яңа кайтарылган җайланма белән таныштыра баш технолог Равия Усманова.

"Здоровье"нең еллар буена сыналган үз икмәк пешерү сере белән дә кызыксынмый кала алмыйбыз. Уңган хуҗабикәләр гадәттә камыр серләре белән уртаклашырга бик ашыкмыйлар, тик биредә рецепт сер астында түгел. Аннан, асылы белән авыл апаларының элек-электән килгән ипи пешерү рецепты ләбаса бу!

– Без камырны сыек чүпрәдән куябыз. Андый чүпрә камыр ризыкларын кабартып кына калмый, искерми торган һәм шул ук вакытта йомшак та итә, – ди Равия Салихҗановна. – Чүпрә кулланып пешергән икмәктә әчелек күп була, ә ул икмәк ризыкларына оннан күчә торган бәрәңге авыруына каршы да яхшы чара. Шуңа да безнең ипи мондый авыру белән зарарланыр дип курыкмыйбыз.

Ә "Здоровье"да бу көннәрдә яңа ниятләр белән яшиләр. Икмәк заводы янәшәсендә яңа он-кондитер цехы әзер булып килә, биредә җайланмалар да урнаштырыла башлаган инде. Бу цех сафка басу исә нурлатлыларны үзебездә җитештерелгән яңа продукция һәм берүк вакытта өстәмә тотрыклы эш урыннары белән дә тәэмин итәчәк.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

"НУРЛАТНЕФТЬ" НГДУСЫНДА

## Яшьләр семинар үткәрде

**15 июльдә "Нурлатнефть" НГДУсының "Чияле Алан" базасында "Татнефть" ПАОсы яшь белгечләре Үзәк Советының "Скважиналарга агымдагы һәм капиталь ремонт" секциясе буенча семинары үтте.**

Эксперт комиссиясе тыңлау өчен әлеге семинарга катнашуга тәкъдим ителгән 37 эшнең 15сен сайлап алды. Докладчылардан тыш, семинарга "Татнефть" ПАОсының структур подразделениеләреннән, бүлентекле җәмгыятьләреннән һәм идарәче сервис компанияләреннән дә тыңлаучылар килгән иде.

Семинарны баш инженеры – "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигының производство буенча урынбасары Равил Әхмәдиев ачып җибәрде. Ул кунакларга Нурлат турында кыскача гына сөйләде, яшь белгечләрне предприятие эшчәнлеге белән таныштырды, киләчәккә планнар белән уртаклашты, Ашалчы чыганагында скважиналар төзүдәге яңа юнәлешләр турында бәян итте.

Фатиха сүзләреннән соң, гамәли өлеш башланды – докладчылар төрледән-төрле һәм кызыклы тәкъдир итүләрдән файдаланып, үз эшләрен тәкъдим иттеләр. Эксперт комиссиясе әгъзалары эшнең мөһимлеген һәм актуальлеген генә түгел, ә теманың ачылышын, шулай ук икътисади нәтиҗәлелеген дә бәяләделәр. Нәтиҗәдә, алар 5 чыгышны "Иң яхшы эш өчен" дипломы белән билгеләп үттеләр, алар арасында "Нурлатнефть" НГДУсы ЦТРСы мастеры Ринат Вәлиәхмәтов та бар иде. Ул "Югары үзлелектәге нефть скважиналарын үз көчләрең белән ремонтлауны оештыру" темасына чыгыш ясады. Барлык 15 катнашучыга да семинарда катнашканлык турында сертификат, ә җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

Аннан яшь белгечләр семинарларын Ашалчы чыганагында дәвам итте. Биредә "Нурлатнефть" НГДУсының катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыруда җылыту ысуллары службасы начальнигы Игорь Купцов семинарда катнашучыларга югары үзлелектәге нефтьне чыгару һәм аны әзерләү процессы турында сөйләде. Ә НГДУның скважиналар ремонтлауны оештыру бүлеге начальнигы Руслан Әбләмитов катнашучыларны АПРС-40Н авыш җайланманың эш принцибы белән таныштырды, аны ясаучылар, җайланманы куллангандагы кимчелекләр һәм уңай моментлар турында сөйләде.

Ашалчы чыганагына экскурсия күп кенә яшь белгечләр өчен яңалык иде әле, шуңа да сораулар күп һәм кызыксыну зур булды. "Нурлатнефть" НГДУсының яшь белгечләр Советы рәисе Рәшит Бакиров әйтүенчә, мондый семинарлар уздыруның дәрәҗәсе елдан-ел арта – тәкъдир итүләр дә кызыклырakka, матурракка әверелә бара, темалар да киңәя.

Марина **КОРНИЛОВА**,

"Нурлатнефть" НГДУсының яшьләр лидеры

Реклама хокукында



ҖИҢҮЧЕЛӘР АРАСЫНДА
РИНАТ ВӘЛИӘХМӘТОВ ТА БАР (УРТАДА)

**"Здоровье" ООО***сында* <u>*икмәк һәм икмәк-күмәч*</u> *әйберләре еллар буена сыналган рецептлар буенча пешерелә. "Здоровье"дан – сыйфат һәм киң ассортимент. Заказлар өчен тел.:* **95–014.**

*Реклама*

## Эштә дә, тормышта да бергә



АПАЛЫ-СЕҢЕЛЛЕ ФӘНИЯ ИБӘТУЛЛИНА
ҺӘМ РАМИЛӘ ХӘЙРУЛЛИНА

**Бертуганнар Фәния Ибәтуллина белән Рамилә Хәйруллинаны без "Сөләйманов Ә.И" КФХсының Биляр Озеродагы терлекчелек комплексында савым вакытында очраттык.**

Икесе бер савым залында янәшә торып эшлиләр, бирегә Бикүледән килеп хезмәт куялар икән апа белән сеңел. Терлекчелек комплексына эшкә урнашканчы "Нурлат сөте" җәмгыятендә дә бергәләшеп сыер сауган булганнар, хәзер менә биредә дә сменаларын бергә куюларын сораганнар.

– Туганың белән янәшә эшләве бик рәхәт бит. Беребез өлгермәгәндә, икенчебез ярдәмгә килә. Бер-беребезне сүзсез дә аңлыйбыз инде хәзер, - диләр үзләре.

Килешеп эшләгәнгәме, күрсәткечләре дә яхшы Фәния белән Рамиләнең. Монда, әлбәттә инде, тәҗрибәле булуларының да файдасы зур. Әнә, Фәния Ибәтуллинаның сыер савучы булып эшли башлавына 31 ел булган икән инде, сеңлесе дә калышмый – 25 ел стажы бар.

Эштә генә түгел, тормышта да бер-берсенә терәк апа белән сеңел. Икесе дә өчәр балага гомер биргәннәр, гаиләләре белән тату гомер кичерәләр. Ә бүгенге көндә эшле булуларына сөенеп туя алмыйлар. Юкка гына эше барның – ашы бар, димәгәннәр бит инде.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

## ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

# Күңел кушуы буенча

**Промышленный урамы башыннан “Пятерочка” кибете юнәлешенә җәяүлеләрне каеннар аллеясы озата бара.**

Көн эссесендә ышыкланырга да бирегә елышалар, нәни балалары белән саф һава сулап йөрүчеләр дә шактый. Әмма аны кем утыртты икән, дип кызыксынучылар бар микән? Ә бит каеннарга гомер бирүче шунда ук, урам башындагы беренче йортта яшәүче Сергей Кубасов. Бирегә күченүгә үк диярлек яшь үсентеләрне утыртып, үзе үк су сибеп, карап үстергән, шул рәвешле шәһәрлеләргә зур булмаган аллея бүләк иткән ул.

Аннан ерак түгел, Промышленный тыкрыгы башындагы бакча мәйданы буенча да, куелган хезмәте буенча да күпкә колачлырак. Монысы – нурлатлы Нәҗибулла Хәмидуллин тудырган яшел почмак. 2004 елдан бирле куйган хезмәтен санасаңмы...

– Биредә чүп-чар оясына әверелгән сазлык иде. Һәр кичен эчкечеләр җыелып кәеф-сафа кора, иртән бала-чага шунда аунап яткан һәр пычракны кулына ала. Әни мәрхүмә улым, син монда җиләк-җимеш агачлары утырт, әбиләр, олылар нигъмәтен җыеп рәхәтләнсеннәр, диде.



МӘЙДАНЧЫК – БАЛАЛАРНЫҢ ЯРАТКАН УРЫНЫ

Ана сүзе Хәмидуллиннар өчен – закон. Шул фатихадан эшен башлап җибәрә дә Нәҗибулла Хәмидуллович. Ике ел дәвамында биредән төзелеш чүп-чарын чыгара, аннан бакча буласы участокның тирәсен тота, дистәләгән машина туфрак китертә, кое казыта... Бу еллар эчендә ул 3312 төп агач-куак кына утырта! 1 гектарлап мәйдан биләгән бакчада бүген сигез төрле җимеш агачы, каен, тупыл, карагач кебек агачлар, чәчәкләр үсә. Нәҗибулла аганың нияте зурдан: бакча кырыйларына сирень агачларын һәм чәй розаларын күчереп утыртып, аны тагы да матурайтасы килә. Ерганак тирәсенә кагасы калайлары әзер инде, аннан шул биеклектә өслекне тигезләп, декоратив үлән чәчәргә ниятли. Ике ”КамАЗ”лап җир кирәк буласы, әмма бушка берсенең дә булышасы килми икән шул. Бер игелекле ханым аның үтенече буенча өлкәннәргә ял итәр өчен артлы эскәмияләр дә ясатып биргән булган, әмма үз эскәмияләрен куеп караган Нәҗибулла ага хәзер шиккә калган: анда эчкечеләр генә җыелып ята калса?.. Участок инспекторы да бу уңайдан проблема тудырырга теләми икән. Юкса, өлкәннәргә бер дигән ял урыны булыр иде дә бит: үзем булдырам, чит кеше алынса, юкка чыгара булган кадәресен дә, дисә дә, мондый колачлы эшләрне башкарып чыгарга исәнлеге һәм мөмкинлеге ай-һай җитәр микән? Әгәр бакча күмәк көч белән культуралаштырылса, бу микрорайон өчен бер дигән ял урыны булыр иде. Әйтик, Тимерҗанов урамында Әндаровлар утырткан аллея сыманрак. Биредәге 3 еллап элек утыртылган агачлар аллеясы – хәзер нурлатлыларның, бигрәк тә яшь балалы әниләрнең яратып йөри торган ял урынына әверелде. 200дән артык төп агач-куакны сулар сибеп үстерүне исә Ильяс Әндаров бер дә авырсынмыйча башкарды. Ә быел исә әлеге аллеяга матур дәвам да өстәлде: “Нурлатнефть” НГДУсы урамга бер дигән волейбол-баскетбол мәйданчыгы куйды һәм заманча балалар мәйданчыгы җиһазлады.

– Бу урам безнең идарәгә беркетелгән, янәшәдәге йортларда нефтьчеләр яши, – ди “Нурлатнефть” НГДУсы начальнигы урынбасары Ильяс Әндаров. – Урам үзе дә нефтьче, Социалистик Хезмәт Герое Зәки Тимерҗанов исемен йөртә бит. Элмә тактаны да без куйдык, әнә, урамга асфальт та түшәлә. Идарә начальнигы Илгиз Салихов нефтьчеләр карамагында булган урам үрнәк төстә булырга тиеш, дигән бурычны куйды. Яр Чаллыдан 1млн 300 мең сумга сатып алган җиһазларны урнаштыруда предприятие хезмәткәрләре эшләделәр.

Шул рәвешле, шәһәр балалары өчен рәхәтләнеп уйнарлык, спорт белән шөгыльләнерлек мәйданчык барлыкка килде. Таганнар, мини-тренажер, атынгычлар, карусельләр янында балалар тавышы ярты төнгә кадәр тынмый.

– Ике баламны да бирегә алып киләм, – ди ерак түгел яшәүче Алия. – Рәхәтләнеп уйныйлар. Иң мөһиме, җиһазлар балалар өчен куркынычсыз, алар пластик материалдан зәвык белән ясалган.

Ә оештыручыларның исә тагы да планнары бар әле: мәйданчыкта ышык һәм комлык өчен гөмбәләр, әниләргә эскәмияләр урнаштырачаклар, ары таба мәйданчык тирәли велосипедчылар өчен юл ясарга да ниятләре юк түгел.

Шәһәрдә яшел зоналарны арттырып, ямь һәм сәламәтлек өстәүче тынгысызлар да бар, әлбәттә. Шундыйларның берсен без Ипподром урамында очраттык. Бу – яңа урам, йортлар әле төзелеп кенә килә. Ә менә гаҗәеп зәвык белән ясалган чәчәклектән (үпкәләмәсеннәр!) безнең транспорт бокралары да көнләшерлек. Төрле төсләргә буялган машина тәгәрмәчләре ярдәмендә зоналарга бүленгән чәчәклекнең таш түшәлгән сукмагы да, дистәдән артык төрдә чәчәкләре дә, җимеш агачлары да бар. Авторы кем дисезме?



ИЛДАР ХӘЙРУЛЛИН ҮЗ ЧӘЧӘКЛЕГЕ ЯНЫНДА

“Нурлат” УТТсы шоферы Илдар Хәйруллин икән ул. Әле салынмаган да йорты янәшәсендәге сак зонасының (электр линиясе үткәнлектән, анда төзелеш эшләре рөхсәт ителми) буш ятуына эче пошып, узган елдан алынган бу эшкә. Участокны гына яллап сөрдергән, калганнарын барысын да үз көче белән башкарган. Ә калганнарын санап китсәңме...

– Посадканы чистарту белән параллель алып барам эшне, – ди Илдар. –Аны корыган агачлардан арындырам, араларына ак сирень утыртам. Әнә, алгы планга инде 30ар төп чыршы, сирень утыртып чыктым, баганага кадәр арада гөлҗимеш куаклары, тагы бер рәт итеп миләш утыртачакмын. Әле матурлык өчен кылганнар утыртасым да килә. Агач-куакларны үзем алып кайтам.

Илдар чәчәкләрне дә кайдан туры килә – шуннан юнәтә икән: әнисе бакчасыннан да күчкән гөлләр бирегә, сатып алганнары да тиз тамыр җәйгәннәр, дуслары да бүлешкән. Биредә бакча җиләге түтәле дә бар, урман җиләге, хәтта каен җиләге дә үзләрен бик яхшы хис итәләр бугай. Чәчәклекнең уртасына Альп тавы сыман зур клумба ясарга ниятли Илдар. Гомумән, планнары зурдан аның. Яшел зона артыннан ук участокны чистартып спорт мәйданчыгы булдырырга да уйлый. Кайдан килгән мондый һәвәслек?

– Мин табигатьне яратам, – ди Илдар. – Без дуслар белән Кычытканлы күленә балыкка йөрибез. Андагы хозурлыкка хәйран калырлык. Шундый матурлыкны кешеләр өчен дә тудырасым килә. Ә табигатьне күрергә, аңларга мәрхүм Николай Кудашов өйрәтте мине. 10 ел аны йөрттем, бик киңкырлы белемле, нечкә күңелле кеше иде.

Безгә калса, матурлыкка тартылу аңа табигатьтән үк салынган булган. Үзе әйтүенчә, “Нурлатнефть” идарәсе рәссамнары белән аралашудан да күп нәрсә алган икән ул.

– Алар миңа яктылыкның төсләргә ничек тәэсир итүен күрергә өйрәттеләр. Гаҗәеп бит! Яшел зонамның төсләрдән балкып торуын телим. Посадканың алдына бер рәт итеп көнбагыш утыртачакмын. Ул чәчәк атканда бигрәк матур бит!

Илдар үз яшел зонасын күңеле кушып һәм күңел биреп башкара, бу эшкә улларын да тарткан. Быел парклар һәм скверлар елы бит, истәлеккә калсын, ди. Кемнәндер ярдәм дә көтми, иң мөһиме, бу матурлыкка зыян гына салмасыннар. Кызганычка каршы, кеше хезмәтен бәяләргә өйрәтү бакча үстерүдән дә кыенрак шул бездә!

Ә инициативалы кешеләрнең кәефен төшермисе иде. Күпкатлы йорт ишек алларында чәчәклекләр үстерүче әбиләребез, агачар утыртучы, балалар мәйданчыкларын карап торучы ир-атларыбыз турында хәбәрләр керә тора бит. Аның экологик файдасы гына түгел, тәрбияв әһәмияте дә зур: шул эшкә тартылга балалар соңрак шәһәр урамнарынна чәчәкләр ботарламаячак, агач ботакла рын йолкымаячак. Юкса, шәһәрнең үзен дә дә һәр елны меңәрләгән төп агачла

**САН**

**Уртача зурлыктагы бер агач тәүлеккә 3 кеше суларлык кислород бүлеп чыгара. Шәһәрдә ишегалларына утыртылган һәр агач 5-10 процент тышкы тавышны йота.**



НӘҖИБУЛЛА ХӘМИДУЛЛИННЫҢ ПЛАННАРЫ ЗУР

утыртыла, өмәләр үткәрелә һәм... байта гы юкка да чыга. Район башлыгы Рави Кузюров та агачларны утырту гына тү гел, тәрбияләүне җиренә җиткере башкарырга кирәклеген еш искәртерг мәҗбүр булды быел. Әнә шундый яшел лекне карап үстерергә күңелләре тар тылган затлар җитмәүдәндер ул. Бые Парклар һәм скверлар елында Нурлатт моңарчы кул тигәнне көтеп яткан пар лар торгызыла, скверлар яңартыла Болары – үзәкләштерелгән тәртиптә, бит һәр күпкатлы йортның ишегалды һәр микрорайонның агач-куак төртер лек буш почмагы бар. Ел дәвамынд шәһәрлеләр әнә шулай үз инициатива лары белән яшел почмак булдырырг теләүчеләргә кушылсалар, Нурлатны йөзе тагы да матураер, һавасы тагы д сафланыр иде.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИН
АВТОР ФОТОЛАР

ЮЛ ИМИНЛЕГЕ

# Сөләйман рульдә булса – юл уңа!



70 ЯШЬТӘ ДӘ ҮЗЕН ЫШАНЫЧЛЫ ТОТА СӨЛӘЙМАН АГА

**Нурлатлы Сөләйман Шаһидуллин машина йөртүче һөнәренә 53 ел гомерен биргән.**

Машина төзелеше үсү тарихының тере шаһиты булган Сөләйман ага шул еллар эчендә бер генә тапкыр да юл-транспорт һәлакәтенә эләкмәгән икән. Сере – юлда игътибарлы булуда. Оста машина йөртүчене 1989 елда ук агросәнәгать комплексының "Һәлакәтләрсез эшләгән өчен" значогы белән бүләклиләр.

Заманында авыл хуҗалыгы вариантындагы "Урал-343"не иярләсә, тора-бара "ГАЗ-51, 53", "ЗИЛ", "Волга" машиналары руле артына утыра. Үзе идарә иткән һәр машинасының җаен, үзенчәлеген белеп торган ул. Шул гомер эчендә "А", "В", "С", "Д", "Е" категорияләрен дә үзләштергән. Һәрвакыт техникасы каралган, машинасы төзек булган Сөләйман абый "тимер атларны" шактый алмаштырса да, холкы үзгәрешсез калган. Исән-имин юлда йөрүенең серен дә юл таләпләрен төгәл үтәүдә дип саный.

– Беркайчан да тизлекне арттырмадым, исерек көе руль артына утырмадым, – ди оста машина йөртүче. – Юлдагы бер генә моментны да күздән ычкындырмаска тырыштым. Тизлек яратучы шоферны күрәм икән, аны уздырып җибәрәм, үзеңә дә, башка юл хәрәкәтендә катнашучыларга да шулай хәерлерәк.

Сөләйман ага төрле урыннарда, төрле техникада эшләсә дә, җаваплы һәм катлаулы һөнәренә тугры калган. Монда төп терәге гаиләсе булган аның. 3 баласы, тормыш иптәше Рәбыйга апа да аңлый торган булганнар үзен.

– Заманында өйдә куна алмаган вакытлары да бар иде. Сельхозтехникада эшләгән вакытларында Казанга аена 12шәр тапкыр бара иде бит. Бу – 24 төн дигән сүз! Рейстан исә һәрчак мине дә, балаларын да сагынып кайта иде. Гаиләбезнең төп таянычы ул. Беркайчан балаларны, оныкларны җәяү йөртмәде. Әле дә алар әтиләренә рәхмәт укыйлар, – дип искә ала җәмәгате Рәбыйга ханым. Яхшы хезмәткәрнең исә җитәкчелек, дус-ишләре, коллегалары арасында да хөрмәте зур була.

Моңа кадәр дәүләт машинасын гына иярләгән профессиональ шофер Сөләйман ага 1980 елда үзенә дә машина сатып ала. Беренче машинасы ВАЗ – 20011не райкомның беренче секретаре Габбас Гыйматдинов бирүен әле дә яхшы хәтерли.

– Районга кайткан 4 машинаның берсен миңа бирделәр, – ди әңгәмәдәшебез.– Ул вакытта акчаң булса да, машина сатып алуы кыен иде бит. Эш урынымнан яхшы һөнәрмән, җаваплы хезмәткәр буларак итәкъдим иттеләр үземне.

Моннан соң ул машиналарын тагын 3 тапкыр яңарткан. Һәр транспорт чарасын күз карасы кебек кадерләп сакларга күнеккән.

– Нурлат зур түгел, сүзнең яхшысы да, начары да тиз йөри бит, – ди Сөләйман абый. – Әгәр машинаң карап йөртелгән, яхшы икән, димәк, син аны отышлы гына сата да аласың.

